ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЙРЯКИ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Новая, д.37, с. Байряки-Тамак, 423964

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЙРӘКӘ-ТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Яңа урамы, 37йорт, Бәйрәкә-Тамак
ав., 423964

Тел.:(85593) 5-13-25, факс:5-13-24, e-mail:Btam.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**№ 2** **29.01.2025**

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкәтамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, гражданнар җыеннарында кабул ителгән 2024 елның 18 ноябрендәге 7 санлы, 2024 елның 19 ноябрендәге 9 санлы, 2024 елның 19 ноябрендәге 11 санлы карарларны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыюның кушымтада бирелә торган тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге муниципаль районның рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы З.М.Әгълиева

ИНН 1642004868

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2025 елның 29 гыйвар
2санлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яше тулган һәр граждан, гражданнар җыенында катнашу-катнашмауларына һәм тавыш бирүдә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә, 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 20 мартына кадәр үзара салым акчалары түләүне башкара.

3. Гражданнарның түбәндәге категорияләре үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:

а) көндезге бүлектә белем алучы студентлар;

б) I төркем инвалидлар;

в) махсус хәрби операциядә катнашучылар;

г) Бөек Ватан сугышында һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларның тол хатыннары;

д) Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр.

4. Түбәндәге очракларда нигезле сәбәпләр булганда:

а) яшәү урыны буенча озак вакыт тормау,

б) авыру,

гражданнарга түләүне гариза нигезендә өч айдан да артмаган вакытка кичектерергә мөмкин.

5. Бер тапкыр түләнә торган түләү турында хәбәрнамә (искәртү) бланкы гражданнарга мәгълүмат стендларында бастырып чыгару һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерү юлы белән, шулай ук кул куеп тапшыру, я почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (искәртү) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, бер тапкыр түләүнең тулы яисә киметелгән күләме, аны түләү вакыты булырга тиеш.

6. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына керә.

7. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясарга, почта күчерүләрен башкарырга хокуклы оешмалар (исәп-хисап оешмалары) аша акча күчерү юлы белән башкарыла.

8. Түләү фактын акча керү турындагы касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслый торган башка документлар раслый.

9. Гражданнарның үзара салым акчалары билгеләнгән вакытта кертелмәгән очракта, алар законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Башкарма комитетының 2025 елның 29 гыйнвар 2 санлы карарына 2 нче кушымта

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге бюджетына
үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
____ санлы
ХӘБӘРНАМӘ (ИСКӘРТҮ)

Түләүченең Ф.И.А. ____________________________________________________
Адресы: ____________________________________________________________
_____________________________________________ нигезендә ____________________Сезгә
_______________елның “___”_____________кадәр үзара салым түләү буенча узган җыен чараларын гамәлгә ашыру буенча түбәндәге реквизитлар буенча бер тапкыр түләнә торган сумма күчерергә кирәк:

Банк получателя
БИК

Алучы
Счет номеры №
ИНН КПП
КБК
ОКТМО
Билгеләнгән түләү

Җитәкче ______________________________________________________
М.У. (имза) (имзаны раслау)

- - - - - - - - - - - - - - - - - кисү линиясе - - - - - - - - - - - - - - -

Бәйрәкәтамак авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү турында
№ _________________ санлы хәбәрнамә (искәртү)
(муниципаль берәмлек исеме)
________________ сум күләмендә
Түләүченең Ф.И.А. ____________________________________________________
Адресы: ____________________________________________________________
«__» _______________ 20__ елны ________________________________ алдым
(түләүченең имзасы)

*Искәрмә. Мәгълүмат түләүчегә шәхси тапшырылган очракта, аерым корешок тутырыла һәм Бәйрәкәтамак авыл җирлеге Башкарма комитетында кала.*